Татарстан яшьләре

№ 80

(8352)

ШИМБӘ

7 июль, 1990 ел

Бәясе 2 тиен.

● ВЛКСМның ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКА КОМИТЕТЫ ОРГАНЫ ● 1920 ЕЛНЫҢ 22 ГЫЙНВАРЕННАН БИРЛЕ ЧЫГА ●





Моңарчы без качаклар турында телевизордан күреп яки радиодан ишетеп кенә белә идек. Бу проблема безнең республикада да чынбарлыкка әйләнде. Пәнҗешәмбе көнне Казанның Ирек мәйданында Кавказ арты республикаларыннан күчеп кайткан татарлар пикет үткәрделәр. Анда катнашучылар качаклар өчен махсус статус булдыруны һәм ТАССР Министрлар Советы каршында махсус комиссия төзүне таләп иттеләр.

Айгөл ШӘРӘФИЕВА.



Рамил ГАЛИЕВ фотосурәтләре.



ЭСТОНИЯ ЮГАРЫ СОВЕТЫНДА

Шушы көннәрдә Эстония ССР Югары Советы сессиясе Эстониянең Дәүләт куркынычсызлыгы комитетын, матбугатта дәүләт серләрен саклау идарәсен һәм хәрби комиссариатын тотуга республика бюджетыннан акча бүлеп бирүне быелның яртысыннан туктату турында карар кабул итте. Моның өчен 60 депутат тавыш бирде. Шул рәвешчә янга калдырылган акчаны хөкүмәтнең резервтагы фондына күчерү күздә тотыла.

(«Советская молодежь» газетасыннан).

МӘККӘДӘГЕ ФАҖИГА

Согуд Гарәбстаны Эчке эшләр министры принц Нәиф ибн Әбдел-Әл-Согуд үткән дүшәмбедә Мәккәдә булган фаҗига вакытында 1426 хаҗ кылучының үлүе турында белдерде.

Мәккәдәге фаҗигага дучар булучылар арасында совет мөселманнары юк.

(«Советская Россия» газетасыннан).

ОСВОД КИСӘТӘ

Балалар су коена...

Эссе җәйдә иң рәхәте нәрсә? Мәгаен, су коенудыр. Су безне эсседән коткарса да, кайвакыт игътибарсызлыгыбызны кичерми. Тикшерүләр күрсәткәнчә, суга батып үлүчеләрнең 75 проценты нәкъ менә җәйгә туры килә. Мәсәлән, былтырның июнендә генә дә республикабыз сулыкларында 60 тан артык кеше һәлакәткә очрады, аларның 15 е — балалар. Быелгы нәтиҗәләр дә шатландырмый. Июнь чагыштырмача салкын һәм бу вакытта сулыкларда куркынычсызлык айлыгы игълан ителгән булса да, инде 7 бала батып үлде. Балаларның һәлакәтенә, беренче чиратта, алар үзләре түгел, ә олылар гаепле. Олыларның битарафлыгы, игътибарсызлыгы гаепле.

Былтыр җәй Татарстанда 50 дән артык бала суга батып үлде. Юк, бу саннар, нишләптер, күпләрне борчымый. Балаларны су коену культурасына, йөзү серләренә өйрәтү турында уйларга ашыкмыйбыз. Шулай эшләгәч, бәхетсезлекләр тагын булачак...

Рәис ШӘРӘФЕТДИНОВ,
ОСВОДның республика советы инструкторы.

РЕПЛИКА

„Сусадым, су бирсәнә"

(«ТАТАРСТАН ЯШЬЛӘРЕ», 67 НЧЕ САН)

Менделеев районының Ижевка авылындагы «Татминводы» заводы бүген үз мөмкинлекләреннән шактый аз күләмдә продукция җитештерә. Монда завод җитәкчелегенең, аерым алганда, аның элеккеге директоры Р. Латыйповның башбаштаклыгы зур комачаулык тудырды. Үз буйсынуындагы «Кызыл шәрык» производство берләшмәсе җитәкчелеге өчен заводтагы хәлләр бик яхшы таныш булса да, анда аларга күз йомып яшәделәр.

«Сусадым, су бирсәнә» исеме белән басылып чыккан мәкаләдә сүз шушы хакта барган иде. Татарстан агропромышленность комитетының «Идел» агропромышленность комбинаты генераль директоры урынбасары Ф. Мөхәммәтҗанов имзасы белән алынган җавапта кимчелекләрне төзәтү юнәлешендә ник берәр чара күрелүе турында әйтелсен? Дөрес, Р. Гыйниятуллинны эштән алу турындагы А. Айбатов биргән законсыз боерык АПК тарафыннан юкка чыгарылган. Тик бу турыда мин үзем үк мәкаләдә язган идем бит.

Мәкаләдә заводта реконструкция һәм кайбер төзәлеш эшләре башлануы турында да язылды. Иптәш Мөхәммәтҗанов әлеге төзелешләрне тизрәк тәгәлләү өчен кайдан һәм нинди материал табу, заводны бүгенге кризис хәленнән чыгару өчен нинди конкрет тәкъдимнәр эшләнүе турында әйтергә батырчылык итмәгән.

Һәм, ниһаять, «Татминводы» заводының элеккеге директоры Рәшит Латыйповның хезмәт урыныннан үз максатлары өчен файдалануын АПК, нигәдер, «казып чыгармаска» тырыша, ә хокук органнарыннан бу хакта хәбәр алынмавы белән котылып калырга җыена, күрәсең. Югыйсә Татарстан агропромышленность комитетыннан һәм район финанс бүлегеннән барып тикшерү уздырган контроль-ревизия комиссиясе Р. Латыйповның 9 мең сумнан артык акча-финанс махинацияләре турында акт төзеп кайтты бит.

«Идел» АПКсының генераль директоры урынбасары Ф. Мөхәммәтҗановка да матбугатта басылып чыккан материаллар белән эш иткәндә, кичәге стереотиптан арынып, бүгенге көнгә кайтырга вакыт.

Әлфия ХӘНӘФИЕВА.

Әнвәр ӘХМӘТҖАНОВ

Җирлеге җирлек түгел

Айкыйбыз гына дөньясын
Тәнкыйть төрәне белән:
Котырган чүп үләннәрә
Авалар берәм-берәм.

И авыз ерган булабыз,
Килде лә ирек диеп,
Менә, ичмасам, явызның
Кирәген бирдек диеп.

Каралып калган була җир,
Куана сабанчылар.
Баксаң, дөнья без сөрүдән
Үзгәрмәгән тамчы да.

Тирәнгә киткән тамырлар
Эһ тә итмәгән ласа.
Тармаклана төшә биреп,
Кабаттан җирне баса.

Күрәсең, җирлеге инде
Шифалы сәмсезләргә.
Бу җирлектә тернәкләү юк
Безләргә һәм сезләргә.


Куәсе беткән лә җирнең,
Шау черемәдән тора.

Баш белгечләр белмәс
серен,
Башлы белгечтән сора.

— Йөз генә түгел бу җирне,
Ботарга йөз дә бер кат,
Мәгънә чыгачак түгел,—ди,
Өметен җуйган бер карт.

Алар монда нилэр генә
Үстереп карамаган.
Тик өметләр чәчәк түгел,
Яфрак та яралмаган.

Булмастыр әр-яңа баштан
Туфрагын яңартмыйча,
Яңа тәр тәрән чыгарып,
Мең кабат җан атмыйча.



Тау башында тора ялгыз кабер...



Мин аны балачактан ук хәтерлим. Зөбәйдә кабере дип йөртәләр иде. Сабый чакта юа җыеныннан кайтучы атлы кунакларны нәкъ шул кабер торган тау астындагы басу капкасын ачып каршылый, ә аннары алар яудырган конфет-прәннекләрне аның янәшәсендәге яшел чирәмлектә утырып ашый идек.

Җиде юл чатындагы кабернең чардуганы яшел чирәм төсле яшелгә буялган, уртасында биек, киң ябалдашлы ап-ак бөдрә каен үсеп утыра иде ул чакта. Кабер янынңан үтүчеләр, мөгаен, аның матурлыгына күз салмый калмаганнардыр. Күз салганнардыр да: «Монда нинди зат ята икән? Бу кабер нигә ялгыз икән?» — дип уйлаганнардыр.

Мин дә бик яшьли белергә тырышкан идем ул кабернең серен. Тик аны инде үсеп җитеп, авылым мәктәбендә укытучы булып эшли башлагач кына белә алдым. Белдем һәм бу турыда балаларга да сөйләдем, география дәресләрендә экскурсияләргә алып чыккач, аларны шушы кабер янына алып бара торган булдым. Чөнки аңа исем биргән Зөбәйдәнең җирдә калдырган эзләре мәктәп, мәгърифәтчелек белән бәйле.

...Зөбәйдә — Зинаида Васильевна Тутаева (Бочкарева) Казан шәһәрендәге күренекле сәүдәгәр, чукындырылган татар Василий Кузьмич Бочкарев гаиләсендә туа һәм заманы өчен укымышлы, зирәк кыз була. Ул үсеп җиткәндә Василий Кузьмич бик зур йолым түләп керәшенлегеннән баш тарта һәм ислам диненә кире кайтып, мөселманча Госман Барбашевка әйләнә. Шул чакта кызына да мөселманча «Зөбәйдә» дип исем куштыра.

Бераздан Зинаида-Зөбәйдәне Сабадагы эре сәүдәгәр Кәрәмулла Тутаевка кияүгә бирәләр. Ләкин яшь кәләшкә ире белән озак яшәргә туры килми. Кәрәмулла сугышка китә. Анда өлкән офицер дәрәҗәсенә күтәрелә. Әмма туган җиренә әйләнеп кайта алмый, сугыш кырында ятып кала. Фронттагы батырлыклары өчен ул зур бүләк — икенче дәрәҗә Георгиев тәресе белән бүләкләнгән, үзе үлгәч бу бүләк аның хатыны Зөбәйдәгә тапшырылган була.

Шул чорларда безнең авылда яшәгән бай сәүдәгәрләрнең берсе Хөрбатулла Рәхимҗанов сәүдә эшләре белән Казанга баргач, якын дусты Госман Барбашев аңа яраткан кызы Зөбәйдәнең тол калуы турында әйтә. Хөрбатуллага исә бу көтелмәгән бәхет булып яңгырый. Һәм ул, дустының кайгысын уртаклашкандай: «Әфәндем Госман, минем бертуган энем Зарифулланың җәмәгате Фатыйма да ике баласын калдырып гүр иясе булды бит әле...» — ди.

Госман сәүдәгәр дустының тел төбен шунда ук аңлап ала. Бераздан: «Әллә соң, кордаш, бу ике тол җанны ярәштереп, башлы-күзле итәбезме?» — дип тәкъдим ясый.

Авыл сәүдәгәре моңа «биш куллап» риза була.

Шулай итеп, шәһәр кызы Зөбәйдә безнең авылга килен булып төшә. Ятим калган ике кыз баланы үз балаларыдай тәрбияли. Зарифулла белән бик тату, матур яшиләр алар. Зирәклеген, укымышлылыгын, кешелеклелеген күреп, авыл кешеләре Зөбәйдәне бик тиз үз итәләр. Авылда әйбәт итеп русча укый-яза белүче, русчаны су эчкән кебек сөйләшә алучы берләнбер кеше Зөбәйдә булган. Хатларга адрес язарга кирәк булса да, авылга рус кешесе килсә дә Зөбәйдәгә йөгерә, аны хөрмәтләп чакыра торган булганнар. Һич арттырып әйтү түгел, ул чакта авыл кешеләренең күбесе туганнан үлгәнчегә кадәр беркая чыгып йөрмәгән бит. Мөхәммәтһади абзый кебек кайберәүләр хәтта, «Ни бар икән дөньяда?» дип, «дөнья читен» янгын каланчасына менеп карый торган булганнар...

Ул чактагы маҗараларны авыл кешеләре мәзәк итеп сөйлиләр... Бервакыт авылдан үтеп баручы руслар, арба тәртәләре сынгач, Ризатдин мулла өенә кереп ярдәм итүен сораганнар. Мулла исә бернәрсә дә аңламый, олы кызын Зөбәйдәләргә йөгертә. Зөбәйдә чакырылмаган кунаклар белән әйбәтләп сөйләшеп, аларның йомыш белән аптырап кергәннәрен белдерә. Ризатдин хәзрәт лапас түбәләрендәге запаслардан бер тәртәне аларга биреп җибәрә.

Тагын бер вакыйга. Берчак безнең авылның өч егете — Гаяз, Котдус һәм Фәтхелбаян Красный Борга ашлык илткәндә рус авылына чәй эчәргә керәләр. Араларында русчаны яхшы белүче Фәтхелбаян арба тәгәрмәче ватылып артта кала. Котдус белән Гаяз фатирга кергәч, йорт хуҗасына йомышларын аңлата алмыйча байтак җәфа чигәләр. Шулай да рус карчыгы ахырда «самовар» сүзен ишеткәч, егетләрнең ни теләгәннәрен төшенеп ала. Чәй кайнап чыккач, егетләргә чәйгә салырга сөт тә кирәк була бит. Монысын инде һичничек аңлатып бирә алмыйлар. Шунда байтак азаплангач, «сөт» сүзен русча белмәгән егетләрнең берсе дүрт аяклы мал булып баса да, мөгрәп куя, Котдус аны савып күрсәтә. Хуҗа хатын башта тораташ булып ката, тик бераздан эшнең асылына төшенеп, шаркылдап көлеп җибәрә һәм тегеләргә сөт кертеп бирә...

Көлсәң көл, еласаң ела, дигәндәй, ул вакыттагы авыл тормышыннан мәзәк булырлык кыйссаларны күп сөйлиләр. Һәм моның белән минем шуны әйтәсем килә: Зөбәйдә шундый хәлдәге кешеләргә бик нык ярдәм итә.

Әнә шулай безнең якларда үз кешегә әйләнеп, ире Зарифҗан үлгәч укытучылык иткән җирдән Зөбәйдә китмәгәндә үлеп китә. Авыл кешеләре өчен генә түгел, күрше-тирәләргә дә зур югалту була бу. Шуңа күрә Зөбәйдәне җирләргә иң мөхтәрәм кешеләр җыела. Тик кәфен тегәргә материал эзләп актарынганда, сандык төбеннән «тавык тәпие» — тәре килеп чыга. Кәфенлек эзләүче остабикәнең куллары калтырый башлый, ул тәмам куркуга төшеп, югалып кала. Аның янына карчыклар җыела, араларында кайберләре «Аллам сакласын! Аллам сакласын!» дип укына башлыйлар. «Зөбәйдә мөселман булмаган бит! Урыс маржасы! Шулай булмаганда, сандыгында тәре саклар идемени?!» Хәбәр яшен тизлеге белән авылга таралып өлгерә. Әлбәттә, олы муллага да барып җитә. Ул катгый карар ясый: «Кяферләрне мөселман зиратына күмү хәрам!»

Бөтен авырлык Зарифҗанның абыйсы Хөрбатулла картка кайтып кала. Мәетне аның подвалына төшереп, кар базыннан алып чыгылган боз «суыткычка» куялар. Карт шул ук көнне губернатордан мәетне күмү өчен җир сорарга чыгып китә. Ничек итсә итә, өч көннән рөхсәт алып кайтып җитә.

— Губернатордан рөхсәт бар... Зөбәйдәне җиде юл чатына күмәргә куштылар, — ди Хөрбатулла, җыелган халыкка рөхсәт кәгазен күрсәтеп.

Авыл старосталары мулла кушуы буенча Хөрбатуллага Зөбәйдәне күмү өчен урын күрсәтәләр... Шулай итеп, үлгән иренә бирелгән бүләкне гомеренең якты истәлеге итеп саклаган Зөбәйдә искелекнең, наданлыкның корбаны була.

Югыйсә Зөбәйдә мәгърифәтче генә түгел, ике милләт арасындагы дуслык җепләрен ныгытучы бер зат. Аның халык күңелендә онытылмас якты истәлеге хәзер дә шул турыда сөйли.

Сәйдел ЗАРИПОВ.
Мөслим районы,
Вәрәшбаш авылы.



...Самолетыбыз Каһирә өстеннән оча. Аста—гадәти булмаган шәһәр. Тирә-ягы—сап-сары ком, тереклек иясеннән мәхрүм ителгән җансыз үлем чүле белән әйләндереп алынган бушлык. Ә шәһәр бер-берсенә терәлеп диярлек урнашкан төрле биеклектәге соры йортлардан, кая карама, күкне тишеп кергән биек-биек мәчет манараларыннан һәм зәп-зәңгәр булып җәйрәп яткан бассейннардан тора. Анда-санда гына күзгә ташланган яшеллек, агачлар таш кала эчендә гел югалып кала кебек. Ниһаять, без, бер группа совет журналистлары, борынгы Мисыр башкаласы, атаклы пирамидалар шәһәре Каһирә җирендә. Самолеттан чыгуга, эссе саунага килеп кергән кебек буласың.

Кондиционерлардан салкынча һава өреп торган автобус белән кунакханәгә юнәләбез. Аэропорттан чыгып унбиш минутлап буш чүл юлы белән баргач, яшеллеккә чумып утырган ике-өч катлы яшел виллалар шәһәрчеге башлана. Бу — Гелиополь — Каһирәнең иң матур һәм иң бай торак кварталы. Бер якта таш коймалар белән әйләндереп алынган яшел бакча эчендә Мисыр Гарәп Республикасы Президенты Х. Мөбарәк апартаментын карап узабыз.

Шәһәр уртасына барган саен урамнар киңәя, озына. Ямьсез соры йортларның тигез түбәләрендә кирпеч, балчык өемнәре, чуп-чар күзгә ташлана, әйтерсең аларның өске катлары җимерелеп хәрабәләр барлыкка китергән.

Автобусыбыз тар гына урамда урнашкан «Индиана» кунакханәсенә бик авырлык белән барып җитте. Урамның ике ягы буйлап тезелеп киткән төрле маркадагы машиналар кара-каршы очрашкан транспортны үткәреп җибәрү өчен зур комачаулык тудыралар.

Бераз алгарак китеп, беренче көнне үк игътибарны җәлеп иткән транспорт чаралары турында әйтми булмый. Биредә юл йөрү кагыйдәләрен үтәү, урам аша светофорга карап чыгу юк дәрәҗәсендә. Җәяүлеләр, машиналар никадәр күп йөреп торса да, берни булмагандай урамны аркылы кисеп чыгалар. Ник бер шофер берәр сүз әйтсен яки артыңнан кычкырып калсын... Бездәге шикелле җәяүлеләргә пычрак чәчрәтеп, тузан туздырып чабучы машиналар күренмәде анда. Ә инде болай да тар урамнар бигрәк тә кичләрен ике яклап тезеп куелган транспорт белән тулгач, шоферлардан аерата зур осталык сорала. Катлаулы лабиринт арасыннан узган төсле, бер машинаны да бәрдермичә үтәргә кирәк.

Кунакханә янында гына яңа йорт төзеп яталар, балчык, ком өемнәре урамны тагын да кысрыклаган. Биредәге төзүчеләр һәм кунакханә янында буталып йөргән гарәпләр көн саен килеп торучы туристларга күнегеп беткәннәр, автобустан төшүгә үк аларның кайсы илдән килүләрен белеп торалар. Безне дә «рус», «русска» дип каршыладылар. Бераздан барысы да аңлашылды: гарәпләрне чит ил туристларыннан бигрәк тә руслар ныграк кызыксындыра икән. «Русска, бизнес есть?» дип арттан ияреп йөри башладылар. Кунакханә белән бер бинаның подвалында урнашкан базар хуҗасы Ибраһим бик җитез булып чыкты. «Ченч» дигән сүзнең мәгънәсе «әйбер алыштыру» икәнлеген дә без иң элек Ибраһимнан ишеттек. Русчаны аз-маз аңлый үзе. «Водка есть? Шампан есть?» дип сорашына: «Водка хәрам, — дим Ибраһимга. — Алла рөхсәт итми». Бу сүзләрнең мәгънәсенә төшенеп җиткәч, Ибраһим нишләргә белмичә миңа төртеп күрсәтеп: «Муслиман? Әлһәмделилла», — дип, ике куллап күрешергә үрелә. Ә инде азмы-күпме белгәннәрне укып күрсәткәч, балаларча шатланып, үзе дә кушылып дәвам итә башлый.

Группадашларым «ченч» ясарга өйрәнеп беттеләр. Кая карама, кара-тут йөзле гарәпләр белән Совет иленнән килүчеләр арасында «бизнес» бара: кем нәрсәнедер акчага сата, кем нәрсәнедер алыштыра. Тик совет товарлары бик арзан бәяләнә биредә. Сүземнең нәкъ шушы темадан — сату-алу, базардан башланып китүен абайламый калуым тикмәгә түгел. Чөнки яшереп торырга һич урын юк: совет туристлары чит илгә баргач иң элек рухи, культура ихтыяҗларын канәгатьләндерү турында түгел, ә нинди дер әйбер сатып алу турында хыялланалар. Үсеп килүче илләр рәтенә кергән Мисырда да бу хакта бик яхшы беләләр. Миңа безнең илгә карата чит ил кешеләрендә шундый уй формалашу





Польша бездән еракмы? Ике ил арасындагы чакрымнарны саный китсәң, ерактыр да... Ә менә ул илдә дусларың күбәйсә, дуслык хисләре ерак араларны да якынайта икән.

«Октябрьнең 40 еллыгы» исемендәге пионер лагеренда ял итүчеләр менә шул хакыйкатьне күңелләреннән кичерделәр. Чөнки биредә Казан пионерлары белән бергә Ломжа воеводалыгының Граево шәһәреннән килгән поляк балалары да ял итә. Җыр-биюләр, күңелле уеннар, җәйнең матурлыгы — бар да уртак.

А. АНДРОНОВ фотосы.

Чаллыда—татар театры

. Ниһаять, ниһаять! Чаллыда кайчан профессиональ татар театры булыр дип көтә-көтә көтек булып беткән җәмәгатьчелекнең, шәһәр тамашачыларының хыяллары чынга ашып килә. Халык булачак театрның хәзерге заман таләпләренә җавап бирердәй сәнгатьчә югарылыкта булуын тели. Шушы максатны күздә тотып, Чаллыда татар яшьләр театры оештырыла. Яңа театр артистларга конкурс игълан итә. Конкурста театраль белеме булган 18 дән 35 яшькәчә һәркем катнаша ала. Шулай ук махсус белеме булмаган талантлы яшьләр дә конкурска кертеләчәк.

Театраль конкурс быелның 1 июленнән 1 августка кадәр дәвам итәчәк. Ярышта катнашырга теләүчеләр Чаллы шәһәренең мәдәният бүлегенә килергә тиешләр. Кабул итү вакыты иртәнге сәгать 9 дан кичке 5 кә кадәр.

Безнең адрес: Чаллы, Яңа шәһәр, Тынычлык проспекты, Җәмәгать оешмалары йорты, 3 нче кат, мәдәният бүлеге.

Сәләтле яшь дуслар, сезне яңа театр көтә!

Фаил ИБРАҺИМОВ,
театрның художество җитәкчесе.

аеруча гарьлек булып тоелды. Бу безнең система турында сөйләүче, аның хәерче хәлендә икәнлеген күрсәтүче ачык дәлил иде. Шуңа күрә һәрвакыт күземә карап «русска» дип эндәшүче гарәпләргә»: «Мин— муслиман», — дип, Россиядән килүемне кире кагарга тырыштым. Ә мөселман халкына мөнәсәбәт биредә искиткеч яхшы. Кибеткә, базарга кергәч тә, мөселман булганым өчен, сатучылар белән озак сатулашырга туры килмәде, алар товар хакын байтакка киметеп саттылар. Ләкин Мисырда бер генә нәрсә дә бушка бирелми. Хәтта 1,5 литр төче суны да бер фунт (безнең 1 сум 3 фунтка тигез) акчаңны түләп а л ы р г а кирәк. Ул гына да түгел, алайболай гарәп кешесе белән фотога төшәргә уйласаң, ансат кына котыла алмыйсың: акча түләргә яки ниндидер бүләк бирергә кирәк. Пирамидалар янына баргач чак кына хурга калмадым: матур итеп бизәлгән дөягә атланган бер гарәп егетен чакырып фотога төшкән идем, теге ачуланып нәрсәдер сөйли-сөйли, артымнан килә башлады. Тәрҗемәчене дәшеп китермичә чара калмады. Дөя хуҗасы түләргә куша икән. Әле ярый сумкамда бер агач кашык бар иде, шуны биреп котылдым...

Мисыр пирамидалары турында китаплардан укып әллә ни тәэсирләнеп булмый икән. Ә менә барып күргәч!.. Кешенең бөек акылы белән ничәмә мең еллар элек Гиза калкулыгында торгызып бастырылган әлеге пирамидалар мине бер мизгелгә тынсыз-өнсез калдырды. Бу — бөек цивилизация тарихы, дөнья, тормыш башланган җир. Борынгы мисырлылар кешенең үлгәннән соң яшәвенә нык ышанганнар. Алар мумияләштерелгән тәннең, билгеле бер догалар укыганнан соң, мәңгелеккә әверелүенә инанганнар. Кеше үлгәч, аның җаны тәненнән аерылып чыга һәм төрле җиргә сәяхәт кыла, җан күмелгән җиргә әйләнеп кайтып тәнне тапмаса, бу аның өчен бик авыр хәл булган дип уйлаганнар. Нәкъ менә шуның өчен Мисырның власть башлыклары һәм түрәләре үлгәннән соң тәннәрен мумияләштереп куя һәм таш сыннарын җимерелүдән саклау өчен үзләренә төрбәләр — бинасыман эшләнгән кыйммәтле каберләр төзеткәннәр. Пирамидалар исә барыннан да ышанычлырак төрбә ролен үтәгән. Ә аларга үтеп керү юлы нык яшерелгән һәм адаштыргыч булган. Мисырның башкаласы Каһирә шәһәре урнашкан уңдырышлы туфраклы Нил елгасы үзәнлекләрендәге комлыкларда үлем шәһәрләре төзелгән, фиргавеннәр үзләре исән чакта ук пирамидалар корганнар.

Гиза калкулыгында IV династия фиргавеннәренең мәһабәт пирамидалары тезелеп киткән. Иң өлкән Хеопс пирамидасының биеклеге — 136 метр. Хеопс кешелек дөньясында иң зур һәйкәлне салдырып калдырган. Аның мәйданы Римдагы Изге Петр соборы, Милandagы Флоренция соборы, Лондондагы Вестминстер сарае һәм Изге Павел соборы урнашкан мәйданнарга бәрабәр. Хеопсның коллары бу әкияттәгедәй биек корылманы төзү өчен 3 миллион данә таш блок җыйнап китергәннәр. Аерым блокларның авырлыгы 30 тоннага җиткән. Ә пирамиданың нәкъ уртасында тулы зурлыгында фиргавеннең мумиясе мәңге саклanырга тиеш булган.

Тар һәм тәбәнәк кенә түшәмле коридор буйлап сузылган баскычтан пирамиданың иң өске өлешенә — фиргавен мумиясе ятарга тиешле таш табут урнашкан бүлмәгә күтәреләбез. Коридорда тынчу. Ярым бөгелеп биек баскычлардан күтәрелү бөтен хәлне ала. XIX гасыр башында ук өлеге күмү бүлмәсенә күтәрелгән галимнәр таш табутта мумиянең булмавын ачыклаганнар. Ул пирамида астындагы җир асты төрбәсендә дә табылмаган.

Хеопс үзе исән чакта ук төзелгән өлеге пирамидада өзлексез 20 ел буе 300 мең кеше эшләгән. Әгәр дә таш блокларны күтәреп кайткан вакытта берәр кол хәле бетеп үлсә, аны пирамиданың нигез буена салганнар. Һәм ул тәнен козгыннар йолыккалап, сөякләрен шакаллар ташып бетергәнчегә кадәр шунда торган. Меңләгән кешеләр шулай һәлак булган...

IV династия хакимлек иткән елларның ахырында халык рәхимсез Хеопсның мумиясен алып юкка чыгарган. Шуннан бирле аның җаны тәнен таба алмыйча адашып йөри имеш. Икенче пирамида «Бөек Хефрен» пирамидасы дип йөртелә. Үзенең әтисе Хеопска хөрмәт йөзеннән Хефрен аны бераз кечерәк итеп төзеткән. Пирамиданың нигезе һәрьяклап 216 шар, биеклеге — 135 метр. Аның өслеге шомартып ялтыратылган ташлардан торган. Бераз читтәрәк Микеринос пирамидасы — өченче бөек төрбә. Дөньядагы җиде могҗизаның берсе буларак тарихка кергән Гиза пирамидалары арасында ул кечерәге саналса да, мөгаен, иң тәэсирләндерә торганы шушыдыр. Чөнки ул пирамидалар турындагы бөек идеянең ахыры булып тәгалләнә. Төзеп бетергәннән соң коллар, гранит тау битләренә төшеп, үзләре башкарган корылмага шаккатып карап торганнар дип сөйлиләр. Әйе, гаҗәпләнмәслек, сокланмаслыкмыни бу мәһабәт пирамидаларга?! Безнең эрага кадәр биш мең ел элек Хеопс, Хефрен, Микеринос хакимлек иткән чорда ук кешеләр нинди гаҗәеп могҗиза тудыра алганнар! Шунысы таң калдыра: ул заманнарда, бернинди техника, механизм, ташларны кисү, тигезләү, шомарту өчен махсус кораллар булмаган чорда да, бернинди цементсыз-сылаусыз, таш өстенә таш куеп төзелгән бит алар! Чиста граниттан эшләнгән матур-матур плитәләр Асуандагы атаклы таш чыгару урынынннан көймәләр белән Нил елгасы буйлап китерелгән.

Үлемсезлек турында хыял... Бу хыялны тормышка ашыру өчен, бальзамлаучылар (бальзамлау серен алар гына белгән) үле фиргавеннәрнең гәүдәсен ике ай буе мумияләүгә әзерләгәннәр: йөрәк белән бөерләрдән кала, эчтәге бөтен органнар алып ташланган. Без бу бөек эшләрне башкаручыларга кызганып карарга тиеш түгелбез. Алар безнең тирән ихтирамыбызга һәм соклануыбызга лаек: ул ерак замандагы кешеләр үзләренең үлемне җиңә алуларына нык ышанып яшәгәннәр! Тикмәгә гарәп мәкалендә: «Дөнья вакыттан курка, ● вакыт пирамидалардан курка», — диелми.

Гиза пирамидаларын узып, Саккара һәйкәлләренә юнәләбез. Үле Сахара чүлләренә биредән унбиш чакрым гына ара кала. Сары ком таулыклары арасына җиткәч, кыздырылган мич эченә кергән кебек буласың. Ник бер агач, берәр үлән заты күренсен! Күзләрне сукырайтырлык дәрәҗәдә аксыл сары ком чүле уртасында — үлем шәһәре. Менә шушы юллардан фиргавеннәрнең мумияләрен мәңгелек ял урынына илткәннәр. Биредәге иң борынгы баскычлы пирамида III династиягә нигез салучы фиргавен боерыгы буенча төзелгән. Җир астындагы төрбәләр дә шарсыман гөмбәзләр, биек-биек колонналар белән эшләнгән. Соры, кызыл, кара төстәге граниттан таш табутлар тезелгән, аларның бальзамланган үгез гәүдәләре куелган капкачлары 60 шар тонна булган дип сөйлиләр. Таш табутлар, таш төрбәләрнең стеналары колонналар, төрле төстәге буяулар белән бизәп язылган иероглифлардан, барельефлардан тора. Бик борынгы заманнарда яшәүчеләрнең культурасын, нәфис һәм искиткеч гүзәл сәнгать осталыгын, гаҗәеп архитектура элементларын күреп һич айный алмыйча йөрим. Булса да булыр икән ул заманнардагы кешедә талант, осталык, серлелек!

Искәндәрия (Александрияне гарәпләр шулай дип йөртәләр) шәһәрендә Ватык Савытлар урамы бар. Борынгы мисырлыларның бу урамга ни өчен мондый исем биргәнлекләрен озак еллар белүче булмаган. Бервакыт бер ишәк тирән коега егылып төшкән. Шуннан соң гына әлеге тирән коеның катакомба икәнлеге ачыкланган. Биредә дә бик бай кешеләрне күмү өчен җир астында өч катлы таш табут төзү урыны эшләнгән. Үле гәүдә әлеге коедагы суга ыргытылган, ул табут урнаштырылган урынга агып чыккач, бөтен шартын китереп мумияләп һәм статуялары белән шушы җир асты катакомбасына куелган. Үлгән кешенең туганнары кайгыларын уртаклашу өчен махсус бүлмәгә җыйналганнар. Алып килгән ризыкларын ашап-эчкәч, савыт-сабаны икенче мәртәбә кулланмас өчен, шушында ватып калдырганнар. Шуңа күрә бу катакомба урнашкан урамга «Ватык савытлар урамы» исеме бирелгән икән.

Әлфия САМАТ.
(Ахыры бар).

Яңа партия төзелде



9 июньдә Әстерханда «Ислам яңаруы» («Исламское возрождение») партиясенең оештыру съезды булып узды. Илебезнең төрле төбәкләрендәге мөселман җәмгыятьләреннән 183 вәкил яңа партиянең уставы һәм программасын к а б у л итте. Шулай ук координацион совет сайланды. Аның әгъзалары үз араларыннан партия өмирен билгеләделәр. Бу исемне Әхмәт-кади Октаев алды.

Иң күп делегатлар җибәрүчеләр арасында Таҗикстан (66), Дагстан (60) һәм Чечен-Ингушетия (38) бар иде. Мәскәүдән — дүрт, Карачай-Черкессиядән, Азәрбайҗаннан һәм Ставрополь краеннан — икешәр, Краснодар краеннан һәм Татарстаннан берәр делегат килде.

Съезд җиңел генә узмады. Шәһәр властьлары аны оештыручыларга т ө р л е авырлыклар тудырырга тырыштылар. Алар делегатларның бернәрсә хәл итмичә кире кайтып китүләре өчен барысын да эшләргә омтылдылар. Шулай да съезд җыелды. Хәер, алдан билгеләнгән ике көн урынына ул эшен бер көндә, 6 сәгать эчендә тәгәлләргә мәҗбүр булды.

Равил ТАҖЕТДИН
фоторепортажы.

ТВ
АТНАЛЫК ПРОГРАММА

ДҮШӘМБЕ

9 ИЮЛЬ

I ПРОГРАММА

6.30 — «120 минут». 8.35 — Мультфильм. 8.50 — футбол. Дөнья чемпионаты. Финал. 11.05 — С. Орехов уйный (җиде кыллы гитара). 11.25 — «Гади дә, гаҗәп тә». 12.30 — «Вакыт». 15.30 — «Яңалыкларның телевизион службасы». 15.45 — балалар өчен фильм. 16.15 — «Компьютер белән диалог». 17.00 — документаль фильм. 17.25 — «Балалар сәгате». 18.30 — «Вакыт». 19.00 — «Без һәм экономика». 19.30 — «Поэзия минутлары». 19.35 — «Азия тавышлары». 20.00 — «Тойгы тәрбияләү». Нәфис фильм. Франция. 1 нче серия. 21.00 — «Вакыт». 21.45 — «Коллаж». 21.50 — «Актуаль интервью». 22.00—«Мәскәү — Брюссель антикүпере». 3 нче кисәк. 22.25 — «Кеше бәхете өчен уйлап табарга». 22.30 — «КВН-90».

II ПРОГРАММА

8.00 — иртәнге гимнастика. 8.20 — концерт-очерк. 8.55 — балалар өчен фильм. 10.00 — документаль фильм премьерасы. 10.35 — «Клиника». Нәфис фильм. 11.50 — телефильм. 12.50 — «Бу фантастик дөнья». 13.20 — документаль фильм премьерасы. 13.40 — «Яңабаштан яшәү». Нәфис фильм. 17.00 — П. И. Чайковский исемендәге IX халыкара музыка конкурсында. 17.30 — «Яз». Мурманск. 17.55 — «Табигать ярдәм көтә». 18.30 — «Вакыт». 19.00 — «Коллаж». 19.55 — «Хәрәкәт куркынычсызлыгы өчен». 20.00 — «Тыныч йокы, нәниләр!» 20.15 — «Тапшыру эфирга узды...» 3 нче чыгарылыш. 20.40 — А. С. Пушкин исемендәге уйлап табу сәнгате музее концертларында. 1 нче тапшыру. 21.40 — «Иллюзион». «Рязань хатыннары». Нәфис фильм.

КАЗАН КҮРСӘТӘ

17.05 — «Сезнең өчен очрашу: композитор А. Луппов». 17.50 — «Кыйссаи Йосыф». 18.30 — «Вакыт». 19.00 — «Татарстан». 19.30— «Әлли-бәлли-бәү». 19.40 — Әлмәт районының Сөләй Мәдәният йорты үзешчәннәре концерты.

СИШӘМБЕ

10 ИЮЛЬ

I ПРОГРАММА

6.30 — «120 минут». 8.30 — Документаль фильм. 9.15 — «Җырга багышланган гомер». А. Стрельченко җырлый. 9.55 — Мультфильмнар. 10.20 — «Дөнья тирәли». Альманах. 11.20 — «Балалар сәгате». 12.20 — «Коллаж». 12.30 — «Вакыт». 15.30 — «Яңалыкларның телевизион службасы». 15.45 — балалар өчен фильм. 16.15 — «ТелеЭКО». Журнал. 16.45 — «Объектив». 17.20 — «Поэзия минутлары». 17.25—«Исәнме, музыка». 18.30 — «Вакыт». 19.15 — «Политик диалоглар». 20.00 — «Тойгы тәрбияләү». Нәфис фильм. 2 нче серия. 21.00 — «Вакыт». 21.45 — «Аргентина ритмнарындагы танго». 22.30 — «Сүз». Әдәби-нәфис программа. 00.30 — «Яңалыкларның телевизион службасы».

II ПРОГРАММА

8.20 — «Крош каникуллары». Нәфис фильм. 1 нче серия. 9.35 — ритмлы гимнастика. 10.05 — «Рязань хатыннары». Нәфис фильм. 11.30 — документаль фильмнар. 12.15 — «Цирк җәнлекләре». 13.00 — «Балалар җырларының Мәскәү конкурсы». 13.45 — «Бурыч». Нәфис фильм. 16.55 — «Безнең фондтан». Г. Малер. 6 нчы симфония. 18.30 — «Вакыт». 19.00 — ритмлы гимнастика. 19.30 — «Янарыш». 20.00 — «Тыныч йокы, нәниләр!» 20.15 — «Коллаж». 20.20 — «Мин 37 нче елдан...». 20.55 — П. И. Чайковский исемендәге IX халыкара музыка конкурсында. 21.40 — «Авыр еллар». Нәфис фильм. 1 нче серия.

КАЗАН КҮРСӘТӘ

17.00 — «Ералаш» киножурналы. 17.15 — керәшен татарларының фольклор коллективлары концерты. 18.30 — «Вакыт». 19.00 — «Татарстан». 19.30 — «Шигърият». Р. Вәлиева. 19.45 — «Әлли-бәлли-бәү». 19.55 — «Алабуга: кичә, бүген, иртәгә». 21.00 — язучы К. Кәримов белән очрашу.

ЧӘРШӘМБЕ

11 ИЮЛЬ

I ПРОГРАММА

6.30 — «120 минут». 8.35 — «Сүз». Әдәби-нәфис программа. 10.35 — «Исәнме, музыка». 11.35 — Документаль фильм. 11.55 — фильм-концерт. 12.30 — «Вакыт». 15.30 — «Яңалыкларның телевизион службасы». 15.45 — Балалар өчен фильм. 16.45 — «Музыка хәзинәләре». В.-А. Моцарт симфонияләре. 17.25 — «Балалар сәгате». 18.30 — «Вакыт». 19.00 — Н. Латинский уйный (скрипка). 19.30 — — «Очрашудан соң очрашу». Тамашачыларның хатларына педагогия фәннәре докторы Г. А. Китайгородская җавап бирә. 20.00 — «Тойгы тәрбияләү». Нәфис фильм. 3 нче серия. 21.00 — «Вакыт». 21.45 — «Коллаж». 21.50 — «Актуаль интервью». 22.00 — «Җыр-90». 23.00 — «Архитектура театры герое һәм корбаны». Архитектор Е. Баженов турында.

II ПРОГРАММА

8.20 — «Крош каникуллары». Нәфис фильм. 2 нче серия. 9.25 — «Чыганаклар». 10.00 — документаль фильм премьерасы. 10.20 — «Авыр еллар». Нәфис фильм. 1 нче серия. 12.20 — А. Алексин. «Кинога барабызмы?» Мәскәүнең яшь тамашачылар театры фильм-спектакле. 13.25 — концерт. 14.05 — «Игорь Саввович». Нәфис фильм. 1 нче серия. 17.00 — «Янарыш». Чехов шәһәренең язмышы турында. 17.40 — Татарстан телевидениесе программасы (Казан). 18.30 — «Вакыт». 19.00 — футбол. СССР чемпионаты. ЦСКА — «Черноморец». Тәнәфестә — «Тыныч йокы, нәниләр!» 20.55 — «Коллаж». 21.00 — «Сезне Свердловск опера театры чакыра». В. Лобачевның «Антигона» операсыннан өзекләр. 21.40 — «Авыр еллар». Нәфис фильм. 2 нче серия.

КАЗАН КҮРСӘТӘ

17.00 — «Татарстан». 17,35 — тапшырулар программасы. 17.40 — Татарстан телевидениесе программасы (М.).

ПӘНҖЕШӘМБЕ

12 ИЮЛЬ

I ПРОГРАММА

6.30 — «120 минут». 8.35 — «Архитектура театры герое һәм корбаны». Архитектор Е. Баженов турында. 10.05 — мультфильмнар. 10.30 — хореография композицияләре. 11.20 — «Балалар сәгате». 12.20 — «Коллаж». 12.30 — «Вакыт». 15.30 — «Яңалыкларның телевизион службасы». 15.45 — балалар өчен фильм. 16.45 — «Сакла һәм тапшыр». 17.30 — мультфильм. 17.40 — «...укалтыга кадәр һәм өлкәнрәк». 18.30 — «Вакыт». 19.00 — «Прогресс.

(Ахыры 4 биттә).

(Ахыры. Башы 3 нче биттә).

Информация. Реклама». 19.30 — документаль фильм. 20.00 — «Тойгы тәрбияләү», Нәфис фильм. 4 нче серия. 21.00 — «Вакыт». 21.45 — «Актуаль интервью». 21.55— «Сез моны булдыра аласыз». Аукцион.

II ПРОГРАММА

8.20 — «Крош каникуллары». Нәфис фильм. 3 нче серия. 9.30 — «Баян» рус халык оркестры концерты. 10.15 — ритмлы гимнастика. 10.45 — «Авыр еллар». Нәфис фильм. 2 нче серия. 12.10 — документаль фильм. 12.20 — «Үзебез белән ата мәче алып барабыз». Балалар өчен нәфис фильм. 13.50 — «Игорь Саввович». Нәфис фильм. 2 нче серия. 17.00 — «Ак болан» (Якут әкияте). 17.25 — «Ингерманландия җире». (Ленинград). 17.55 — ритмлы гимнастика. 18.30 — «Вакыт». 19.00 — футбол. СССР чемпионаты. «Спартак» — «Торпедо». Тәнәфестә — «Тыныч йокы, нәниләр!» 20.50 — «Коллаж». 20.55 — «Яхшы сәламәтлек сезгә, доктор Сарчук». 21.40 — «Ерма». Нәфис фильм

КАЗАН КҮРСӘТӘ

17.05 — мультфильмнар. 17.25 — З. Сәхабиева җырлый. 17.55 — «Татарстан».

ҖОМГА

13 ИЮЛЬ

I ПРОГРАММА

6.30 — «120 минут». 8.35 — «Аргентина ритмнарында танго». 9.20 — документаль фильм премьерасы. 9.30 — «...уналтыга кадәр һәм өлкәнрәк». 10.15 — «Сез моны булдыра аласыз». Аукцион. 11.25 — «Ел фасыллары». Июль. 12.30— «Вакыт». 15.30 — «Яңалыкларның телевизион службасы». 15.45 — балалар өчен фильм. 16.15 — документаль фильм премьерасы. 16.35 — «Образ». Өлкән класс укучылары өчен әдәби тапшыру. 17.15 — мультфильм. 17.25—«Яшә, Җир!». 18.30 — «Вакыт». 19.00 — мультфильм. 19.10 — А. Миронов исемендәге актерлык җырлары конкурсы. 19.35— «Прогресс. Информация. Реклама». 20.05 — «Тойгы тәрбияләү». Нәфис фильм. 5 нче серия. 21.00 — «Вакыт». 21.45 — «Коллаж». 21.50 — «Болар булды... булды... булды...» 22.10 — документаль фильм премьерасы.

II ПРОГРАММА

8.15 — «Крош каникуллары». Нәфис фильм. 4 нче серия. 9.25 — «Лейгарид» фольклор ансамбле концерты (Таллинн). 9.50—документаль фильм. 10.15 — «Умырзая-90». 10.45 — «Ерма». Нәфис фильм. 12.10 — Ф. Әмиров. «Низами хатирәсе» симфониясе. 12.40 — документаль фильм премьерасы. 13.15 — «Кармен». Телефильм. 14.15 — «Игорь Саввович». Нәфис фильм. 3 нче серия. 17.00 — Таҗикстан телевидениесе программасы (Дүшәнбе). 17.30 — «Күпер». Аерылып калган Корея гаиләләре проблемалары турында. 18.30 — «Вакыт». 19.00 — Режиссер М. Соосаара фильмнары. Документаль фильм. «Киху утравы хатыннары». 20.00— «Тыныч йокы, нәниләр!» 20.15 — «Коллаж». 20.20 — «НЛО: игълан ителмәгән визит». 4 нче тапшыру. 21.10 — нечкенә концерт. 21.55— «Спорт һәркем өчен».

КАЗАН КҮРСӘТӘ

17.05 — фильм-концерт. 17.30 — «Банкротлыкка бер адым». Тәнкыйть материаллары эзеннән. 17.50—«Җомга көн кич белән». Альманах. 18.30 — «Вакыт». 19.00 — «Татарстан». 19.30 — Р. Дәминов җырлый.

ШИМБӘ

14 ИЮЛЬ

I ПРОГРАММА

6.30 — «120 минут». 8.30 — «Безнең бакча». 9.00 — «Кеше. Җир. Галәм». 10.00 — «Партнер». 10.30 — «Хайваннар дөньясында». 11.30 — «Өлкән уллары». Нәфис фильм. 1, 2 нче серияләр. 14.00 — Останкиноның Концерт студиясендә СССРның атказанган тренеры А. Гомыльский белән очрашу. 14.55 — мультфильм. 15.05 — «Политик диалоглар». 15.35 — Режисер Н. Губенко фильмнары. «Тормыш, көз яшьләре һәм мәхәббәт». 17.15 — «Халыкара панорама». 18.00 — Телевизион компания кичәсе. «Канал плюс» Совет телевидениесендә. 21.00 — «Вакыт». 21.45 — «Канал плюс» тапшыруының дәвамы.

II ПРОГРАММА

8.15 — «Мәхәббәт аңлашу». Субтитрлар белән нәфис фильм. 1 нче кисәк. 9.25 — документаль фильм премьерасы. 9.45 — мультфильм. 9.55 — «Коллаж». 10.00 — «Педагогика һәркем өчен». 11.00 — «Дуслык» видеоканалы». 14.30 — «Советлар Россиясе». Видеоканал. 17.00 — «Прогресс. Информация. Реклама»». 17.30 — «Югалганнарны эзләү юлында». 19.00 — волейбол. Дөнья лигасы беренчелеге. Ирләр. Ярымфинал. 20.00 — «Тыныч йокы, нәниләр!» 20.15— «Шолохов язы» (Ростов-Дон). 20.45 — документаль фильм. 21.00 — «Вакыт». 21.45 — «Пресс-клуб».

КАЗАН КҮРСӘТӘ

17.05 — «Әткәм-әнкәмнең теле». Татар теле дәресләре. 1 нче уку елы. 11 нче дәрес. 17.30 — Х. Бегичев җырлый. 18.00 — «Мамадыш районында очрашу». Мамадыш районында социаль-экономик үзгәрешләр. 19.00 — «Татарстан». 19.30 —«Хәрәкәт куркынычсызлыгы өчен». 19.50 — «Әлли-бәлли-бәү». 20.00 — «Тыныч йокы, нәниләр!» 20.15 — «Кешегә адреслана». Авылларга газ кертү. 20.45 — өлкәннәр өчен мультфильм.

ЯКШӘМБЕ

15 ИЮЛЬ

I ПРОГРАММА

8.00 — «Спорт һәркем өчен». 8.15 — ритмлы гимнастика. 8.45 — «Спортлото» тиражы. 9.00 — «Иртә таңнан». 10.00 — «Ватанга хезмәттә». 11.00 — иртәнге күңел ачу программасы. 11.30 — Сәяхәтчеләр клубы. 12.30 — «Сәламәтлек». 13.15 — «Музыкаль киоск». 13.45 — Д. Биссет әкиятләре буенча мультфильмнар. 14.15 — «Образ». Өлкән класс укучылары өчен әдәби тапшыру. 15.30 — «Авыл сәгате». 16.45 — «Әкиятләр һәм маҗаралар дөньясында». 18.20 — «Поэзия минутлары». 18.30 — «Танылуын телим». Нәфис фильм. 1, 2 нче серияләр. 21.00 — «Вакыт». 21.40 — «Мәңгелек турында фикерләр». 21.55 — «Мәскәү — Брюссель антикупере». 4 нче кисәк.

II ПРОГРАММА

8.20 — «Мәхәббәт аңлашу». Субтитрлар белән нәфис фильм. 2 нче кисәк. 9.20 — документаль фильм. 9.40—Можайскидагы фольклор бәйрәме турында. 10.00 — документаль фильмнар. 10.25 — «Гаилә» телепрограммасы 11.25 — «Коллаж». 11.30 — Сәяхәтчеләр клубы. 12.30 — профессионаллар арасында баскетбол буенча АКШ чемпионаты. 13.00 — волейбол. Дөнья лигасы беренчелеге. Ирләр. Финал. 14.30 — «Советлар Россиясе». Видеоканал. 17.00 — «Планета» Халыкара программа. 18.00 — «ТФ» студиясе». 20.00 — «Тыныч йокы, нәниләр!» 20.15 — «ТФ» студиясе». 21.00 — «Вакыт». 21.40 — «ТФ» студиясе».

КАЗАН КҮРСӘТӘ

17.05 — Кырым татарларының «Хайтарма» җыр һәм бию ансамбле чыгышы. 18.00 — «Палитра». СССРның халык художнигы Х. Якупов. 18.55 — «Панорама». Информацион-публицистик программа. 20.55 — тапшырулар программасы.



Теләктәш

Ике автокаләм, бер суыткыч!

Әйтергә генә ансат бит, ике каләм, бер суыткыч! Телисең икән, рәхим ит, җиһазлы буласың, теләмисең икән — акчалата ал. Йөз тәңкә!

Почта бүлегендә күпләр Шәлвәне отышы белән тәбрикләде. Көнләшеп куючылар да булды. Тик Шәлвә, нишләптер, үзе шат түгел. Ул отышлы билетларын чытырдатып тоткан килеш почтадан чыгып китте.

Бигрәк хәтәр эшли инде безнең газета, телевидение, радио журналистлары. Каян ишетеп өлгергәннәр, кем әйткән. Шәлвәне почта баскычында ук «эләктереп» алдылар.

Чалт-чолт — фотоаппаратлар!

Гыж да гыж — кинокамералар!

Кыштыр-кыштыр — кәгазь-каләм!

Шытыр-шытыр — магнитофоннар!

— Шәлвә иптәш, сез ничек бу бәхеткә ирештегез?

— Әйтегезче, әллә лотерея отуның бер-бер серен беләсезме?.. Сез узган елны да ике палас, бер кул сәгате откан идегез бит!

— ...Акчалата аласызмы, әйберләтәме?

Тагын әллә нинди ахмак сораулар белән күмеп ташлаган булырлар иде, Шәлвә хәбәрчеләрнең ата-бабаларын искә төшереп бер кычкырды да терсәкләре белән этә-төртә камалыштан чыкты.

Ай-һай, безнең «фототелекинорадиогазетакорр» л а р д а н алай тиз генә котылып булыр дип Шәлвә ялгыш уйлаган икән. Хәбәрчеләр көтүе, берсен-берсе таптап, көн каһарманы Шәлвә артыннан ыргылды.

— Иптәш Шәлвә, бер-ике сүз...

— Өч кенә кадр... — дия-дия, хәбәрчеләр янә Шәлвәне сырып алды.

Кемнеңдер:

— Нинди бәхет! — дип кычкырганын ишетте Шәлвә. — Нинди бәхет, утызар тиеннән, туксан тиенгә суыткыч, каләм, келәм... Йөз сум!

Аннан соң кемдер:

— Йөз генә түгел, машина откан, биш мең, ун мең, йөз мең! — дип кычкыра башлады.

Акча суммасы арта барган саен, Шәлвәнең башы ныграк әйләнә иде. Кайсыдыр каһәр сукканы Шәлвәне куып җитеп, бишмәт чабуыннан тотып алды. Шәлвә кинәт ыргылып, хәбәрче кулыннан ычкынды. Һәм, уйлап-нитеп тормастан, ачык капкага атылды. Ул туптуры бәдрәфкә йөгереп керде. Ишек төбендәге чебен өере, Шәлвәдән куркып, мыжгылдап һавага күтәрелде. Шулчак дөнья куптарып ишегалдындагы әнчек эт өрә башлады. Эт тавышынамы, урамда йөгерүчеләрне күрепме, өйдән кешеләр атылып чыкты.

— Янгын бугай! — дип кычкырды иң беренче чыкканы.

— Юк! Акча, машина, ун мең сум! — дип кычкырдылар.

— Карак тотканнардыр!— диде өченчесе.

Шәлвәнең йөрәге күкрәк кесәсендәге калын блокнотын селкетә-селкетә тибә. Тез буыннары калтырый. Ул билетларын шатырдатып тоткан килеш тактага сөялде. Башка вакыт булса, бәдрәф тактасына ясалган абстракция рәсемнәрне карап, әбрәкәй авыз иҗаты һәм дә тыныш билгеләрен укып утырган булыр иде. Бу юлы Шәлвәнең эшләре мөшкелрәк иде шул.

Шулчак бәдрәф ишеге ачылып китте. Шәлвәнең күзләре таныш түгел хатын күзләре белән очрашты. Шәлвә мәгънәсез рәвештә елмайгандай итте. Хатын бик назлы токымнардан булып чыкты бугай:

— Байназар, карак! — дип кычкырды да чүп өеменә ауды.

«Байназар» дигәннәре иләмсез таза гәүдәле ир булып чыкты, яңа гына чәй эчеп утырган җиреннән йөгереп чыккан булса кирәк, юеш майкадан һәм чалбарын бер генә төймәсенә элдергән. Йонлы беләкләрендә тир тамчылары ялтырый. Байназар, нәсел үгезе мөгерәгән тавыш чыгарып, хатынына ярдәмгә ыргылды. Шәлвә, күп уйламыйча, ишектән җәһәт кенә чыкты да бәдрәф түбәсенә сикерде, аннан коймага үрмәләде. Туксан килограмм авырлыктагы Байназар гәүдәсе секундына йөз сиксән чакрым тизлек белән бәдрәф ишегенә килеп бәрелде. Ул арада хәбәрчеләр көтүе ишегалдына атылып керде. Акыра-бакыра йөгерүче Байназарга да, чебен күче сырып алган хатынга да, хәбәрчеләргә дә игътибар итеп тормады Шәлвә, койманың тегә ягына сикерде. Әллә шуны гына көтеп торган, бозау хәтле эт, дәшми-тынмый гына Шәлвәнең лафсан чалбары төбеннән һап! Шәлвә әллә куркудан, әллә хуҗалар сизмәсен дип, кычкырмады. Ул бер кулы белән латарай билетларын тоткан килеш, икенче кулы белән коймага асылынып, эт белән байтак тарткалашты. Этә дә эт булып чыкты, һич кенә дә җибәрми. Чалбары да гади ситсыдан булса, шәп булыр иде. Лафсан бит, эт авызында умырылып калмый. Күтәрелеп кенә җитәм дигәндә, овчарка Шәлвәне кире тартып төшерде. Хәлдән таеп бетте Шәлвә. Һәм кулын ычкындырды.

— Хуҗалар! Ко-откарыгыз! — дип кычкыра башлады ул.

Тик өйдән беркем чыкмый. «Дачага китеп дөмектеләр микәнни?» — дип уйлады Шәлвә... Эт Шәлвәнең лафсан чалбарын ычкындырды да бакча капкасы янына барып ятты. Үзе бертуктаусыз Шәлвәне күзәтә. Шәлвә тормакчы булып кыймылдый башласа, эт аякларына баса да: «Тик кенә ят, ботарлап ташлармын», — дигәндәй, ырылдап куя. Шәлвә эт карашына буйсынып, кире җиргә ята.

Шәлвә өметсезлектән илаулап елап җибәрде.

— Их, эткәй-эткәй, хәлләремне белмисең бит! Кешеләр мине бәхетле дип уйлый. Келәмнәр, сәгатьләр, автокаләмнәр, суыткыч отты, баеды, диләр. Белмиләр минем бәхетсез икәнемне! Их, мәэмай-мәэмай, биш ел хыялландым машина отарга. Биш ел ота алмадым. Я каләм, я кул сәгате отам. Машина юк. Ел саен алтыҗиде йөз сумлык билет алам, биш-алты тәңкәлек отыш чыга. Биш елга ике машиналык акча тоттым.

Эт тә шыңшып куйды. Ул Шәлвәне кызганды бугай, танавын һавага төртеп улады да, иренеп кенә сукмактан читкә китте. Янәсе, юл ачык, китә аласың!

Шәлвә күз яшьләрен сөртә-сөртә җирдән торды. Эт ырламады.

Роберт БАТУЛЛА

Менә шундый мәзәк

Йөремсәк мәзәкләр яратмаган кеше сирәктер ул. Урамда яки транспортта булсын, эш арасында яки мәҗлестә булсын, дус-ишләр дә, беренче генә тапкыр очрашкан кешеләр дә бер-берен яңа мәзәкләр сөйләп көлдерергә тырышалар. Рәхәтләнеп көлү безгә бүгенге авыр тормышыбызны азга гына булса да онытып торырга ярдәм иткәнгәдер, күрәсең, олысы-кечесе, югарыдагысы-түбәндәгесе мәзәк ярата. Врачларның 5 минут көлү кеше организмына фәлән калорий бирерлек ризык ашап куйгандай тәэсир итә дигән фикерләре дә үзенекен итәдер. Тамак мәсьәләсе авырлашканда моны да чуттан чыгарып булмый. Үткен һәм чәнечкелеләрен дә, әдәпсезләрен һәм мәгънәсезләрен дә, эч катканчы көлерлекләрен дә — барысын да халык чыгара. Аларда безнең тарихыбыз, тормышыбыз чагыла.

Бүген без күпчелеге моңарчы пышылдап, үзара сөйләнелгән сәяси мәзәкләр бастыра башлыйбыз һәм газета укучылар үзләре дә ишеткән, белгән мәзәкләрен редакциягә юлларлар дип ышанып калабыз. Өй адресыгызны куймаска да мөмкин.

Балалар бакчасында.

Тәрбияче: Балалар, иң матур балалар уенчыклары кайсы илдә!

Балалар (барысы берьюлы): Советлар Союзында!

Тәрбияче: Ә иң матур балалар киемнәре кайсы илдә!

Балалар (барысы берьюлы): Советлар Союзында!

Тәрбияче: Ә иң бәхетле балачак кайсы илдә!

Балалар (барысы берьюлы): Советлар Союзында!

Арадан Вовочка кычкырып елый башлый.

Тәрбияче: Вовочка, сиңа ни булды!

Вовочка (күз яшьләренә буылып): Советлар Союзында яшисем килә!

* * *

— Иптәш Лигачев, сезнең плюрализмга карата фикерегез нинди!

— Плюрализм турында ике фикернең булуы мөмкин түгел!

* * *

Брежнев үзенең дачасында уянганнан соң ишегалдына чыга. Карый — Карлсон очып бара.


— Син кем! — дип сорый Брежнев.

— Карлсон.

— Нәрсә дигән сүз соң бу! Кем ул Карлсон! Сакчылар кая караган!

— Сез ничек инде мине оныттыгыз, — ди Карлсон, — минем турыда китаплар укымадыгызмы әллә!

— Хм... Карлсон, Карлсон... — дип үзалдына мыгырдана Брежнев. — Ә-ә-ә, Карлсон! Ничек инде онытыйм. Ә сезнең көрәштәшегез һәм дустыгыз Энгельсон кайда соң!



Н. РАЧКОВ рәсеме.

Мөхәррир
Исмәгыйль ШӘРӘФИЕВ
(тел. 53-52-34).

Мөхәррир урынбасары
Миңназыйм СӘФӘРОВ
(тел. 53-07-52).
Җаваплы сәркатип
Рәис НАСЫЙБУЛЛИН
(тел. 53-07-50).

ЯЗЫГЫЗ:
420066 Казан, Декабристлар урамы 2. «Татарстан яшьләре»

ШАЛТЫРАТЫГЫЗ:
Иҗтимагый тормыш мәдәният — 53-07-56 (Фирдә Низамова)
Советлар яшьләр оешмалары — 53 07-52 (Миңназыйм Сәфәров)
Экономика — 53-07-50 (Рәис Насыйбуллин)
Фән уку йортлары — 53 07 54 (Насимә Садыйкова)
Әдәбият сәнгать — 53 07-54 (Илдар Миңгәрәев)
Экология авыл тормышы — 53 07-52 (Әлфия Самат)
Яңалыклар — 53 07 56 (Айрат Сәвый...)
Хатлар әхлак — 53 07 58 (Рина Зарипова Роза Мортазина)
Сәркатип урынбасары — 53 07-50 (Айрат Салаватуллин).
Тәрҗемәче — 53-07-54 (Роза Шәрәфиева)
Корректорлар — 53 07-48 (Илсөяр Гарипова, Альмира Зәйнуллина).
Фотограф — 53-07 48 (Рамил Галиев)
Рәссам — 53-07-50 (Роза Атнагулова)
Машинистка — 53-52-34 (Гөлчәчәк Җәләева).

«Татарстан яшьләре» атнага өч тапкыр чыга. Индекс — 54121.

Редакциянең килгән материалларны рецензияләү һәм кире кайтару мөмкинлеге юк.

ПФ 03635 КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясендә басылды. Казан, Декабристлар урамы, 2. Тираж 285.000. Заказ 3083.